Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«14» ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2020 елның 14 ноябрендә түбәндәге сораулар белән узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1. 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында;

2. 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында..

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 90 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 48 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

1. 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында беренче сорау бунча.

2021 елда үзара салым кертү турында гражданнар җыены каравына чыгарыла торган сорауга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зүзәй авылы чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Зүзәй авылында су белән тәэмин итү объектларының тирә-юнен тәртипкә китерү, ремонтлау һәм төзекләндерү» сүзләрен «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зүзәй авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау, карап тоту, кышын карап тоту:

- Зузеево авылында су белән тәэмин итү объектларының техник документациясен эшләү, ремонтлау, норматив хәлгә китерү, янәшәсендәге территорияне төзекләндерү» сүзләренә алыштырырга.

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 45кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 3 катнашучысы тавыш бирде.

2. 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында икенче сорау буенча.

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенә керүче Зүзәй авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зүзәй авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау, карап тоту, кышын карап тоту:
- Зузеево авылында су белән тәэмин итү объектларының техник документациясен эшләү, ремонтлау, норматив хәлгә китерү, янәшәсендәге территорияне төзекләндерү»:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 45 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 3 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында гражданнар каравына чыгарыла торган мәсьәлә текстына үзгәрешләр кертү турында;

2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча кабул ителгән карарларны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Зүзәй авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.Н. Пинин

Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин